| ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

23 июнь, 2022 ел № 15/11

Шәһәр Советының 2015 елның 28 декабрендәге 5/7 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә автомобиль һәм гомуми файдаланудагы шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртүне оештыру Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 15 апрелендәге 92-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 28 статьясы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2015 елның 28 декабрендәге 5/7 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә автомобиль һәм гомуми файдаланудагы шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртүне оештыру Тәртибенә (Шәһәр Советының 2017 елның 20 июнендәге 17/9, 2017 елның 15 декабрендәге 21/12, 2018 елның 27 апрелендәге 24/9 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) түбәндәге эчтәлектәге 33.2 пункт өстәргә:

«33.2. Юридик затка, шәхси эшмәкәргә, гади ширкәт шартнамәсендә катнашучы вәкаләтле затка бирелгән даими пассажирлар йөртү маршруты буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклык аның гамәлдә булу вакыты озайтылган, даими пассажирлар йөртү маршрутының билгеләнгән тәртиптә үзгәртелгән, юридик зат үзгәртелгән, аның исеме, урнашу урыны адреслары үзгәргән очракта, шулай ук шәхси эшмәкәрнең яшәү урыны, һәм (яки) фамилиясе, һәм (яки) исеме, һәм (яки) атасының исеме үзгәргән, мондый шартнамәдә катнашучылардан берсенең вафатына бәйле рәвештә гади ширкәттә катнашучылар составы үзгәргән очракта яңадан рәсмиләштерелергә тиеш.»;

2) 40 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«40. Юридик затка, шәхси эшмәкәргә, яисә гади ширкәт шартнамәсендә катнашучыларның берсенә бирелгән даими пассажирлар йөртү маршруты картасы

аның гамәлдә булу вакыты озайтылган, транспорт чарасының классы яисә характеристикалары билгеләнгән тәртиптә үзгәргән очракта, юридик зат исемен, урнашу урыны адресларын үзгәрткән очракта, шулай ук шәхси эшмәкәрнең яшәү урыны, һәм (яки) фамилиясе, һәм (яки) исеме, һәм (яки) атасының исеме үзгәргән, мондый шартнамәдә катнашучылардан берсенең вафатына бәйле рәвештә гади ширкәттә катнашучылар составы үзгәргән очракта яңадан рәсмиләштерелергә тиеш.».

2. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының шәһәр төзелеше, шәһәр инфраструктурасын һәм торак-коммуналь хуҗалыкны үстерү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме

Н.Г. Мәһдиев